**/Күренекле шәхесләр/**

## Якташыбыз – сугыш һәм хезмәт ветераны

Гәзитебезнең алдагы саннарында Бөек Ватан сугышында катнашкан якташлар, шул исәптән, сугышчы мөгаллимнәр тормышын яктыртуга зур игътибар бирелде. Бу санда гомерен яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган сугыш һәм хезмәт ветераны **Хәйретдинов Хәлим Шәрәфетдин улы** турында язып үтәрбез.



Хәйретдинов Хәлим аэрофоторазведка буенча алынган сүрәтләрне картага төшерә. 1944 нчы ел.

Хәлим абый 1918 нче елда Түбән Майна авылында дөньяга килә. Аның әтисе Хәйретдинов Шәрәфетдин бабай авылның гына түгел, төбәкнең дә иң күренекле кешесе буларак таныла. Ул 1913-1916 нчы елларда Түбән Майнаның старостасы булып тора. Моңардан тыш волость судьясы, җир банкының ревизия комиссиясе рәисе вазифаларын да башкара. Авылда үзенең кибете һәм авыл хуҗалыгы машиналары була. Шәрәфетдин бабайның Габделнасыйр бабай кызы Мәрфуга белән гаилә кора. Аларның 8 балалары туганы билгеле. Хәлим абый шуларның иң кечесе була.

Шәрафетдин бабай совет хакимиятен кабул итә алмый. Шул сәбәпле аның гаиләсе даими эзәрлекләүләргә дучар ителә. 1931 нче елда аларны, бөтен булган маллары тартып алынып, биш елга концлагерьга җибәреләләр. Лагерьдан Шәрафетдин бабай сәламәтлеге нык какшап кайта һәм озак та тормый үлә. Балалары, авылда төпләнә алмаганлыктан, читтә яшәргә мәҗбүр булалар.

Хәлим абый әле сугышка кадәр үк укытучы һөнәрен алып, Такталы авылындагы җидееллык мәктәпкә эшкә урнаша. Ул чорда Такталы мәктәбе тирә-якта төп белем бирүче бердәнбер мәктәп булган. Шәрәфетдин бабай гаиләсендә педагог һөнәрен сайлаучылар ул гына булмый. Хәлим абыйның олы абыйсы Фәрдетдиннең кызы Әминә апа да гомере буе укытучы булып эшли. “СССР ның атказанган укытучысы” дигән мактаулы исемгә лаек була.

Бөек Ватан сугышы башлангач Хәлим абый 02.04.1942 мобилизацияләнә. География укытучысы һөнәренең хәрби хезмәтендә дә кирәге чыга. Ул 15 нче гвардия Кызыл байраклы артиллерия бригадасы разведка-артиллерия дивизионының фотовзводында фотограф-дешифровщик булып хезмәт итә. Смоленск шәһәрен, Белорусияне азат итү, Көнчыгыш Пруссияне яулап алу сугышларында катнаша. Германия җиңелгәннән соң Япониягә каршы сугышка җибәрелә. Дошман оборона линияләрендәге ут нокталарын төгәл ачыклаганы өчен 2 тапкыр «За отвагу» медале белән бүләкләнә. Сугышны өлкән сержант званиесында тәгәлли.

Демобилизацияләнгәннән соң Хәлим абый Иске Ибрай һәм Такталы авылларында мәктәп директоры булып эшли. Мәктәптән киткәннән соң Такталыда клуб мөдир вазифасын башкара. 1998 нче елда вафат була.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***

**/Безнең спорт/**



Май аенда безнең укучылар катнашкан спорт ярышлары күп булмады. 14 нче майда Норлат шәһәрендә тренер Ф.Т.Мөхәммәтҗанов истәлегенә үткәрелгән милли көрәш буенча турнирда укучыларыбыз **Галимов Рияз, Шичкин Али, Замалетдинов Зөлфәт** һәм **Хәбибрахманов Абдулла** үз авырлыкларында III урыннарны яуладылар. Аларга киләсе бәйгеләрдә уңышлар теләп калабыз.

**/Котлыйбыз!/**

Ямьле май аенда туган көннәрен билгеләп үтүче V сыйныф укучысы **Сафиуллина Кәримәне**, VI сыйныфтан **Вәлиева Мәрьямне**, VII сыйныфтан **Шичкин Алины**, X сыйныфтан **Шичкина Каринаны** һәм XI сыйныфтан **Туктамышева Әминәне** чын күңелдән котлыйбыз. Укучыларыбызга сәламәтлек, тырышлык, укуларында уңышлар телибез.



Башлангыч сыйныфлар укытучысы **Хәйруллина Рузилә апаны** да гомер бәйрәме белән котлап, ныклы сәламәтлек, иҗади уңышлар, озын гомер телибез.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Әминә Туктамышева, Виктория Нукина, Зөлфирә Сафиуллина

**Мәктәп хәбәрчесе**

**№5** (№46) май 2023 ел

**Түбән Майна урта мәктәбе гәзите**

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

## Саубуллашу вальсы

**/Мөхәррир минбәре/**



Кеше гомерендәге ин дулкынландыргыч вакыйгаларның берсе – мәктәп елларының тәмамлануын белдергән Соңгы кыңгырау бәйрәмедер. Бу көнне җиз кыңгырауның моңлы чыңлавы укучының мәктәптән, туган оясыннан аерылуын гына түгел, балачак белән хушлашуын да игълан итә. Шул сәбәпле бу бәйрәмдә катнашучыларның күңелләрен моңсулык биләп ала. Әти-әниләрнең баласының канат астыннан чыгуына уңайсызлануы, укытучыларның алда торган дәүләт имтиханнары өчен борчылуы да кушыла бу кыңгырау тавышына. Шуңа күрә бу бәйрәм башкаларыннан бер үк вакытта тантаналы да, моңсу да булуы белән аерылып тора.

Быел XI сыйныфны – 4, IX сыйныфны 7 укучы тәмамлады. Чыгарылыш сыйныфлар имтиханнарга әзерләнеп, елның узганын да сизми калдылар. Менә инде алар мәктәпнең түрендә – тантаналы линейкада. 24 нче майның кояшлы иртәсендә соңгы кыңгырау тавышы барчабызны да бәйрәм түренә чакырды. Майдан түренә чыгып баскан укучыларның телләрендә укытучыга рәхмәт сүзләре, күзләрендә әти-әнигә караш, күңел түрләрендә “алдагы имтиханнарда сынатмабызмы” – дигән уйлар. Сынатмассыз укучылар, дибез без. Имтихан нәтиҗәләрегез нинди генә булса да, һәр эшнең ахыры хәерле булуын телик. Мәктәптә уку елларында күрсәткән тырышлыгыгыз һәм максатчанлыгыгыз зур тормыш сынауларын да җиңәргә ярдәм итәр, сайлаган юлларыгызда уңышка китерер.

Бу бәйрәм дә, гадәттәгечә, мәктәп директоры чыгышы белән башланып китте. Ул һәр елны чыгарылышларны тирән бер дулкынлану белән котлый. Һәрберсенең уңышларын барлап, яратып, ихластан теләкләрен җиткерә. Җитәкчедән соң сүз алган сыйныф җитәкчеләре, әти-әниләр һәм лаеклы ялдагы ветеран мөгаллимнәр укучылар өчен шатланып, киләчәктә уңышларның тагын да олырагына ирешүләрен теләделәр. Мәктәп белән хушлашучы апа-абыйлары янына беренче сыйныфка баручы нәниләр чыгып басуы бәйрәмгә тагын бер ямь өстәде. Чөнки мәктәпнең киләчәге алар кулында.

Бәйрәмгә үтә дә бер моңсулык өсти торган мизгел – саубуллашу вальсы. Ел саен кабатланса да, һәрьюлы үзенчәлекле итеп башкарыла торган бу чыгыш күз алдыбыздан китми. Ниһаять, бәйрәмнең һәм уку елының ахырын игълан итеп, соңгы кыңгырау яңгырый. Үзләренә алмашка килүче бакча балаларын җитәкләп, чыгарылышлар янәдән мәктәп бусагасын атлап керделәр. Ак юллар сезгә, кадерле укучылар!

***Фәнүзә Гафиятуллина, газетаның баш мөхәррире***

## 2022-2023 нче уку елы нәтиҗәләре

**/Рәсми хәбәрләр/**

Май аеның 23 ендә 2022-2023 нче уку елының нәтиҗәләре чыгарылды. Уку елын 46 укучы тәгәлләде. Укучыларның еллык билгеләре буенче белем сыйфаты 56,8%, өлгереш 100% тәшкил итте. Еллык нәтиҗәләр буенча уку елын гел “5” ле билгеләренә тәмамлаучылар: II сыйныфтан **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**, V сыйныфтан **Закирова Лэйсән**, VI сыйныфтан **Гафиятуллин Фаил**, XI сыйныфтан **Нукина Вика** белән **Туктамышева Әминә**.

Мәктәптән тыш чаралар буенча югары нәтиҗәләргә ирешкән укучылар:

- спорт юнәлешендә – көрәшчеләр **Замалетдинов Зөлфәт**, **Сәгъдиев Рәмзис**, **Хәбибрахманов Абдулла** (IV сыйныф), **Шичкин Али** (VII сыйныф), **Галимов Рияз** (IX сыйныф), **Камалов Илдус** (XI сыйныф), шахматчы – **Гафиятуллин Фаил** (VI сыйныф);
- әдәбият һәм сәнгать юнәлешендә – **Закиров Инсаф** (II сыйныф), **Нурматова Асия** (III сыйныф), **Донсков Артур** (IV сыйныф), **Насыйрова Кәүсәр** белән **Закирова Лэйсән** (V сыйныфлар), **Залиева Вәсилә** (VI сыйныф), **Шичкина Карина** белән **Морадимов Илсур** (X сыйныфлар).

Уку алдынгыларына һәм төрле ярыш-конкурсларда 3 тапкыр һәм аннан да күбрәк урын алучыларга июнь башында узачак балалар сабантуенда мәктәп грамоталары тапшырылачак.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

**/Мәктәп тормышы/**

## Хушлашыр чак җитте дусларым...

### (Чыгарылыш сыйныф укучыларының хушлашу сүзләре)

Әле күптән түгел генә без, нәни сабыйлар булып, беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлап кергән идек. Ә хәзер инде зур кешеләр булып үсеп җитеп, олы юлга аяк басабыз. Шул юлга безне басарга өйрәткән, безгә юл салган һәрбер укытучыга бик зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Аларга киләчәктә түземлек, сабырлык, исәнлек-саулык теләп калам. Шулай ук зур рәхмәтемне безнең пешерүчеләргә белдерәм. Шул 11 ел буе безне тәмле иттереп, сөендереп ашаткан өчен бик зур рәхмәт! Башка укучыларны тырышып укырга, үз максатларына ирешергә чакырам. Киләчәктә аларның имтиханнарын югары балларга тапшыруларын һәм яхшы кеше булып үсүләрен теләп калам!

**Әминә Туктамышева**



Мәктәп еллары озак кебек тоелса да, бик тиз үтә икән. Кемдер укуның тәмен белеп, олы тормыш юлына аяк баса. Ул студент була. Мин дә, күптән түгел генә мәктәп баласы идем. Иптәшләрем белән парта артында утыра идек. Ә хәзер инде үземне бөтенләй башка, зур кеше сыман хис итәм. Безне хәзер алда зур сынаулар көтә. Студент еллары, һөнәр алу. Мәктәп еллары сагынырга гына кала. Мәктәптә алган белемнәр, укытучыларның биргән киңәшләре, сыйныфташлар белән бергә уздырган вакытлар. Барысы да бер мизгел генә булып кала. Аларны искә алып, 11 ел буе укыган мәктәп бусагасын атлап, яңадан 1 нче сыйныф баласына әйләнәсе килә. Ләкин вакытны кирегә әйләндереп булмый шул. Шуның өчен, укучыларга мәктәп елларының кадерен белергә, укытучыларның биргән киңәшләрен тыңларга һәм һәрвакыт үз өстеңдә эшләргә чакырам.

**Вика Нукина**

Әле кайчан гына чәчәк тотып 1нче сыйныфка килгән идек. Ә хәзер инде һөнәри уку йортларына да китәргә вакыт җитте. 11 ел вакытның үткәне сизелмичә дә калды. Мәктәп еллары – ул яшьлекнең иң матур, иң истәлекле чоры. Анда без яңа белемнәр алабыз, дуслар табабыз. Мәктәп безгә максатларга ирешергә булыша. Ләкин нинди генә биеклекләргә ирешсәк тә, уңышлар башында һәрвакытта да укытучы һәм тәрбиячеләр тора. Менә шушы уңышларым өчен аларга олы рәхмәтемне җиткерәсем килә. Безгә тәрбия һәм белем биргән остазларга эшләрендә зур уңышлар, саулык-сәламәтлек телим. Ә укучыларга шуны әйтәсем килә – киләчәктә алачак барлык белемнәрнең нигезе мәктәптә бирелә. Шуңа күрә укытучыларны тыңлагыз һәм тырышып укыгыз!

**Зөлфирә Сафиуллина**



**/Безнең бәйрәмнәр/**

## Җиңү көне чаралары

Май ае башлану белән Җиңү көнен билгеләп үтү өчен төрле чаралар әзерләнә. Быелгысы елда 5 нче майда мәктәп яны бакчасында агачлар утыртылды. Бу чыгарылыш сыйныф укучылары белән берлектә "Җиңү бакчасы" дип аталган акциягә кушылу иде. "Җиңү тәрәзәләре" акциясе дә безнең укучылардан читтә калмады. Сыйныф тәрәзәләрен җиңүгә багышлаган рәсемнәр белән бизәделәр.

Ә инде тынычлык бүләк иткән каһарманнарыбыз барыннан да бигрәк игътибарга, кадер-хөрмәткә мохтаҗ. Бәйрәм якынлашкан көннәрдә, бигрәк тә. Бөек Җиңүнең 78 еллыгы уңаеннан уздырылган бәйрәм чаралары да иң беренче чиратта әнә шул максатны күздә тота. Мәктәбебез һәр елны бу чарага җитди рәвештә әзерләнә. Быелгы чараларны да укучыларыбыз тирә-як авылларга дип тә әзерләде. Яңа һәм Иске Татар Әдәм суы авылларында Җиңү бәйрәмен каршылау чарасы 8 нче майда, ә туган авылыбызда 9 нчы май иртәсендә һәйкәл янында үтте. Башлангыч һәм урта сыйныф укучылары катнашуындагы концерт тематик эчтәлекле, җырлы-биюле булды. Елдагыча "Үлемсез полк" акциясе килгән тамашачыга каһарманнарның исемнәрен янә искә төшерде. Тыл ветераннары сафы гына елдан-ел сирәгәя бара. Мондый чараларда гына түгел, сугыш авырлыкларын җилкәләрендә күтәргән өлкәннәребезгә игътибарыбыз һәрвакыт булсын иде.

***Гөлшат Закирова, башлангыч сыйныф укытучысы***

**/Чал тарихта эзле без/**

## Авылыбызның җир биләмәләре тарихыннан

Авыл халкының төп яшәү чыганагы җир булганлыктан, бабаларыбызның кайсы заманнардан бирле шушы җирләрне биләүләрен ачыклау мөһим эш булып тора. XVI -XVII гасырларда халыкның барлык категорияләре дә җирләрен хакимият тарафыннан бирелгән документлар нигезендә биләгәннәр. Безнең төбәккә патша чиновниклары XVII гасыр урталарында гына килә башлыйлар. Ул заманда бу якларда халык аз яшәгәнлектән, бөтен җирләрне дә исәпкә алу үткәрелми. Яңа күченеп килүчеләр күңелләренә хуш килгән җир тапсалар, шунда төпләнеп авылларын барлыкка китергәннәр.

Безнең авыл халкының үз җирләренә хокукын раслаучы документлары булмаган. XVIII гасыр ахырында уздырылган Генераль межалау вакытында күршедәге Биләр белән җир бәхәсе килеп чыккач, безнең авыл турында ***"...деревень Черемшанов, Студеные Ключи тоже, иначе именуемых Майною, которым писцовых книг или никаких укреплений не имеется..."*** диелгән. Җир биләү хокукын раслаучы документының булмавы безнең авылның XVII гасыр урталарына чаклы, ягъни бу яклар хөкүмәт контроле астына кергәнче үк яшәгәнлеген дәлилли. Биләр белән бәхәсләшкән вакытта Майна халкы исеменнән язган үтенечтә ***"Означенные наши деревни издавна поселением, состоят на землях простирающихся по разным урощищам, которыми как предки наши, ровно и ныне жители владение имеем..."*** дип белдерелә. Бу язмадан күренгәнчә, хәзерге вакытта безнең авыл һәм Чуаш Майнасына караган җирләрне бабайлар элек-электән үзләренең биләмәләре дип санаганнар.

Майна җирләренең чикләрен төгәл итеп межалау XVII-XVIII гасырлар чигеннән башланып китә. 1700 нче елда Әдәм авылына хәзерге Әлки районына караган Суыксу авылыннан 12 йомышлы татар килеп төпләнә. Шуларның җирләрен межалау вакытында Майна белән Иске Әдәм арасындагы җирләрнең хәзерге "Иске гыран" дип аталган узган төгәл чиге билгеләнә. Бу чик 1970 нче еллар башына хәтле үзгәрешсез кала. 1714 нче елда Әдәмсуы авылы җирләренә яңадан межалау үткәрелә. Моңа 35 кешедән торган йомышлы татарлар төркеменең Әдәмсуы биләмәләреннән җир соравы сәбәп була. Бу юлы да безнең авыллар арасындагы чикләр 1700 нче елда билгеләнгәнчә кала. 1714 нче елгы межалау вакытында Әдәмсуы авылы белән чиктәш Чуаш Әдәм Суы, Саурыш һәм Майна авылларының вәкилләре катнаштырылмый. Шул сәбәпле ул авыллардагы халык хәтта атларга атланып, коралланып чыгып межалауны булдырмаска да тырышып караганнар. Ләкин бәхәс барыбер Иске Әдәмнең йомышлы татарлары файдасына хәл ителгән.

1717 нче елгы документта хәзер Чуаш Майнасы урнашкан Чирмешәннең уң ягындагы җирләр Майна ясаклы татарларының биләмәсе дип күрсәтелгән. Ул якта Майна җирләре 1708 нче елда нигезләнгән Түбән Кыдырата авылы биләмәләре белән чиктәш була. Әлеге чикне межалау 1722 нче елда башкарыла.

1772-1800 нче еллар арасында уздырылган генераль межалау вакытында билгеләнгән чикләр совет чорына кадәр гамәлдә була. XVIII гасыр ахырында Биләр кешеләре безнең авыл җирләренә дәгъва белдерсәләр дә, бәхәс безнең бабайлар файдасына хәл ителә. Чөнки ул вакытта безнең авылда дәүләт крестьяннарының җан башына туры килергә тиешле җир иманасы 15 дисәтинәгә тулмыйча, 14,9 дисәтинә генә тәшкил иткән. Патша Павел Інең 1798 нче елгы указы буенча казна авылларында җан башына тиешле җир иманасы 15 дисәтинәлек итеп билгеләнгән. Генераль межалау вакытында Биләр һәм аннан аерылып чыккан отставкадагы солдат авыллары – Шәмә, Горка, Ник. Баран, Дуңгыз җирләре гомуми бер биләмә булар каралган. Хәзерге вакытта Шәмә белән безнең авыл арасындагы чикләр 1800 нче елда тәгаенләнгән межа буенча үтә.

Майна Башы җирләре белән чиккә килгәндә, элек ул тулысынча урман эченнән үткән. Ул урманның Түбән Майнага караган өлеше XIX ахырына ук киселеп, басуга әверелгән. Хәзер "Майна Башы урманы" дип йөртелгән урманның кырые шушы чиккә туры килә. Әлеге чик шулай ук, XVIII гасыр ахырында генераль межалау вакытында билгеләнгән булырга тиеш.

XVIII гасыр уртасында Иске авыл татар һәм чуаш өлешләренә аерылганда тагын җир бүлешү мәсьәләсе килеп туа. Риваять буенча, ул вакытта безнең бабайлар хәзер биләгән җирләрне үзләренә калдыру өчен чуашларны бернечә тапкыр шобага салырга мәҗбүр иткәннәр. Чөнки Чирмешәннең болын ягындагы җирләр тау ягындагы белән чагыштырганда электән үк эшкәртелеп киленгән, тигез, иркен һәм мәйданнары буенча да зуррак. Ул вакытта хәзер Чуаш Майнасы биләгән җирләрнең күп өлешен әле урман каплап торган. Шуның өстенә Югары кырның шактый өлеше, иске авыл урынын да кертеп, татарлар биләмәсендә калган.

1838 нче елга караган мәгълүматлар буенча безнең авыл һәм Чуаш Майнасының гомуми җир мәйданнары Генераль межалау вакытындагы кебек үк 3098 дисәтинә дип күрсәтелгән. Шуларның 1802 се безнең авылга, 1296 сы Чуаш Майнасына караган. 1854 нче елгы картадан Югары кырда чуаш һәм татар чәчүлек җирләрен аерган чик хәзерге межа буенча, ә урман биләмәләренең чиге – Келәүле күл елгасы турысыннан үткәнлеге күренә. Революциядән соңгы елларда чуашлар безнең авылга җир дәгъвасы белдереп, Югары кырдагы 100 гектардан артык җирләрне үз авылларына күчерүгә ирешәләр. Колхозлар башланган чорда Чуаш һәм Татар Майналары арасындагы Югары кырдагы чик хәзерге вакытта ике ерым тирәсенә утырткан посадка турысыннан үткән.

1960 нчы еллар башында Түбән Майна, Такталы, Иске Әдәм һәм Яңа Әдәм колхозлары бер хуҗалыкка берләштерелгәч, элек Иске Әдәмнеке саналган 200 гектар җир безнең авыл карамагына күчерелә. Шулай итеп, Чуаш Майнасына биреп югалткан җирләр Иске Әдәм җирләре исәбеннән арттырып кайтарыла.

***Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты***